ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.08.2018 Казан ш. № 7-6/т

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегендә муниципаль маршрутлар буенча җәмәгать транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның иң чик максималь тарифларын билгеләү турында

«Автомобиль транспорты һәм һәм шәһәр җир өсте электр транспорты уставы» 2007 елның 8 ноябрендәге 259-ФЗ номерлы һәм «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 7 мартындагы 239 номерлы карары, «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законны гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә таянып КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегендә муниципаль маршрутлар буенча автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның иң чик максималь тарифларын әлеге карарга теркәлгән кушымтага ярашлы рәвештә билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль

маршрутлары буенча автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүгә һәм багаж ташуга иң чик тарифларны билгеләү турында» 2017 елның 7 апрелендәге 7-1/т номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
2018 елның 24 августындагы 7-6/т
номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының
«Арча шәһәре» муниципаль берәмлегендә муниципаль маршрутлар буенча
автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм
багаж ташуның иң чик максималь тарифлары

| Транспорт төре | Бер тапкыр баруның һәм бер урынлык багаж алып баруның иң чик максималь тарифы (сум) | |
|---|---|---|
| | транспорт чарасы салонында билет сатып алганда | юлда йөрү өчен озак вакытлы файдаланудагы билет белән түләгәндә 50 һәм аннан күбрәк бару өчен [1] |
| Автобус | 18 | 15 |

<1> юлда йөргән өчен шәһәр эчендә йөрү өчен күрсәтелгән срок дәвамында төгәл билгеләнгән сумма чикләрендә йөрергә хокук бирә торган озак вакытлы файдаланудагы билет белән түләгәндә.

Искәрмә. Багаж ташу бәясе юлда йөрү бәясеннән аерым түләнә.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тарифларны кабул итүне оештыру,
тикшерү һәм документлар белән тәэмин итү бүлеге